**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«15» апреля 2019 с. Тюлячи № 228

Татарстан Республикасы Teләче муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Teләче муниципаль районы җирлекләре бюджетына җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслауга башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2018нче елның 27нче ноябрендәге «Федераль әһәмияттәге Мәскәү шәһәрендә, Мәскәү һәм Калуга өлкәләрендә, шулай ук Татарстан Республикасында (Татарстанда) «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимы кертү буенча эксперимент уздыру турында»гы 422нче санлы Федераль закон нигезендә, һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалын үстерүне стимуллаштыру максатыннан, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирлекләре бюджетына җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслауга башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.
2. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-бюджет палатасы рәисе Р.Р. Яхинга йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы И.А. Миннигулов

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019нчы елның 15.04.2018
228 санлы
карары белән расланган

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирлекләре бюджетларына җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслауга башка бюджетара трансфертлар бирү Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирлекләре бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү механизмын билгели (алга таба - башка бюджетара трансфертлар, муниципаль берәмлекләр).

2. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасында һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалын үстерүне стимуллаштыру максатыннан Теләче муниципаль районы җирлекләре бюджетларына җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслауга бирелә.

3. Башка бюджетара трансфертлар җирлекләр бюджетларына квартал саен, узган кварталдан соң килүче айның 30 числосына кадәр,тиешле финанс елында Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы бюджеты турындагы карар белән тиешле финанс елына һәм план чорына күрсәтелгән максатларга каралган бюджеттан бүленгән акчалар күләме чикләрендә бирелә.

4. Әлеге Тәртип буенча бирелүче бюджет акчаларынбаш бүлүче булып Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-бюджет палатасы тора (алга таба – финанс-бюджет палатасы).

5. Башка бюджетара трансфертларны бүлү Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

6. Башка бюджетара трансфертларның күләме i-муниципаль берәмлек өчен тиешле кварталга түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$МТiкв = НПДiгод – НПДiпт:$$

МТiкв – i-муниципаль берәмлек өчен тиешле кварталга башка бюджетара трансферт күләме, сумнарда;

НПДiел – Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы бюджетына i-муниципаль берәмлек территориясеннән Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә теркәлгән салым

түләүчеләрдән ел башыннан арта барып кергән һөнәри керемгә салым суммасы, сумнарда;

НПДіпт – Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә теркәлгән салым түләүчеләрдән і- муниципаль берәмлек бюджетына кергән,башка бюджетара трансферт бирү максатыннан элек исәпкә алынган һөнәри керемгә салым суммасы, сумнарда;

7. Муниципаль район составына керүче җирлекләргә башка бюджетара трансфертлар бирүнең шарты булып җирлекнең башка бюджетара трансфертлар хисабына гамәлгә ашырыла торган чыгымнары юнәлешен билгеләүче норматив-хокукый актлары булу тора.

8. Башка бюджетара трансфертлар финанс-бюджет палатасы тарафыннан җирлекләр бюджетына Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең җирле бюджет үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачылгантерриториаль органнары счетларына күчерелә.

9. Җирлекләрнең башкарма комитетлары башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында финанс-бюджет палатасына финанс-бюджет палатасы билгеләгән формада һәм тәртиптә хисап бирә.

10. Әлеге Тәртип буенча алынып, агымдагы финанс елының 1нче гыйнварына файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы бюджеты кеременә кире кайтарыла.

Хисап финанс елында файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булуы турындафинанс-бюджет палатасы карары беләнбашка бюджетара трансфертларның калдыгыннан артмаган күләмдәге акчалар агымдагы финанс елында башка бюджетара трансфертлар бирелгән тиешле максатларда, бюджет чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен,җирлек бюджеты керемenә кире кайтарылырга мөмкин.

Әлеге Тәртип буенча алынган башка бюджетара трансфертларның файдаланылмаган калдыгы Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы бюджеты керемено күчерелмәгән очракта, бу акчалар Россия Финанс министрлыгы куйган гомуми таләпләр буенча финанс-бюджет палатасы билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы бюджеты керемено түләтелә.

11. Җирлекләр башкарма комитетлары һәм вазифаи затлар тапшырыла торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы бюджеты керемено бирү шартларын үтәү өчен закон нигезендә җавап тота.

12. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары бозылган очракта тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнары белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы бюджеты керемено күчерелергә тиеш.

13. Әлеге Тәртип нигезендә бирелгән башка бюджетара трансфертларның максатчан файдалануына финанс-бюджет палатасы контрольлек итә.